# РАМАЗАН АЕ УРАЗАСЫНЫҢ ҺӘМ ТӘРАВИХ НАМАЗЛАРЫНЫҢ ФӘЗЫЙЛӘТЕ,

## һәм шуның белән бәйле, кайбер кешеләр өчен яшерен булып калган хөкемнәрне аңлату

Шәех Гәбдүлгәзиз ибн Гәбдуллаһ ибн Бәз

**(Гарәпчәдән тәрҗемә)**

**БисмиЛләһи-р-Рахмәни-р-Рахиим.**

(Рәхмәт иясе һәм Рәхимле булган Аллаһ исеме белән!)

Гәбдүлгәзиз ибн Гәбдуллаһ ибн Бәздән әлеге сүзләр барып ирешкән һәрбер мөселманга! Аллаһ Тәгалә безне дә һәм сезне дә иман әһелләре юлыннан алып барсын, Көръәнне һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ Сөннәтен дөрес аңлаучылардан кылсын! Әмин!

Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Һәм аннан соң:

Әлеге кыска гына булган нәсыйхәт – Рамазан ае уразасының, тәравих намазларының, шушы айда сәваплы гамәлләр кылуда ярышуның фәзыйләте һәм кайбер кешеләрдә аңлашылмаучылык тудырып, алардан яшерен булып калган хөкемнәрне аңлату белән бәйле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ үзенең сәхабәләрен Рамазан ае җитү белән сөендерә торган булган. Һәм аларга, әлеге ай җиткәч, Җәннәт һәм рәхмәт ишекләре ачыла, Җәһәннәм ишекләре, киресенчә, ябыла, шәйтаннар тозакка куела дип хәбәр биргән. Һәм ул әйткән: ***“Рамазан аеның беренче төне җитү белән Җәннәт ишекләре ачыла, бер ишегә дә ябылган килеш калмас, Җәһәннәм ишекләре ябыла, бер ишегә дә ачылган килеш калмас, һәм шәйтаннар бәйләнеп куела. Шул вакытта бер Өндәүче әйтер: “Я яхшылыкка омтылучы – тырыш, я начарлыкка омтылучы – тыел! Һәм [бу айның] һәр төнендә Аллаһ күпмедер кешеләрне Җәһәннәмнән азат итәр”.*** Икенче бер хәдистә пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйткән: ***“Кем Рамазан аеның [көннәрен] Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп ураза белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер, һәм, кем Кадер кичәсен Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп гыйбадәт белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер”.*** Тагын бер хәдистә пәйгамбәребез ﷺ әйткән:

***“Аллаһ Тәгалә әйтте:*** **“Әдәм баласының һәрбер яхшы гамәле өчен әҗер-сәвабы уннан алып җиде йөзгә хәтле арттырып бирелер, бары тик уразадан кала, чөнки ул Минем өчен генә тотыла һәм Мин аңа әҗер-сәвабын Үзем бирермен, [Әдәм баласы] үзенең шәһвәтен, ризыгын һәм су эчү теләген Минем өчен генә калдыра.”** ***Ураза тотучыга ике сөенеч булыр: беренчесе – [кич белән] авыз ачканда, икенчесе – [Кыямәт көнендә] Раббысы белән очрашканда. Ураза тотучының авызыннан килгән ис Аллаһ Тәгалә өчен мускус исеннән дә хуштрак”.***

Рамазан ае уразасы һәм тәравих намазларының фәзыйләте, гомумән алганда, ураза темасына бәйле хәдисләр бик күп. Аллаһ Тәгалә безне шушы айга ирештергән икән, без бу форсаттан файдаланырга, Аллаһ яраткан гамәлләр кылуда ашыгырга,

гөнаһлардан ерагаерга, Аллаһның безгә йөкләгән әмерләрен тиешенчә үтәргә тырышырга тиешбез. Аеруча биш вакыт намазга игътибарыбызны арттырырга кирәк, чөнки бу Ислам диненең нигезе, үзенең дәрәҗәсе һәм мөхимлеге белән ике шәһадәттән[1] соң килә. Шуңа күрә, һәрбер мөселманга, булсынмы ул ир-ат яки хатын-кыз, биш вакыт намазны тиешенчә саклап, хошуглык һәм тынычлык белән үз вакытында үтәргә кирәк. Шулай ук, ир-атлар өчен, намазларны Аллаһны зекер итү өчен төзелгән урыннарда – Аллаһ йортларында, ягъни мәчетләрдә – җәмәгать белән үтәү тиешле. Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтә: **“Намазларны үтәгез һәм зәкәт садакасын бирегез һәм намаз укучылар белән бергә намаз укыгыз”.** (“Әль-Бәкъара” сүрәсе, 43-нче аять), шулай ук: **“Ий мөэминнәр! Намазларыгызга сакчыл булыгыз, ягъни намазны көтеп алып, әүвәл вакытында укыгыз, хосусан икенде намазына игътибар бирегез, бер нәрсә дә сәбәп булмасын намазны калдырырга яки кичектерергә, һәм намаз укыганда Аллаһтан куркып, нык бирелеп укыгыз һәм намазда түбәнчелек белән торыгыз!”.** (“Әл-Бәкъара” сүрәсе, 238-нче аять). Һәм, шулай ук, Аллаһ Тәгаләнең “Әл-Мөэминүн” сүрәсендәге: **“Чынлыкта, мөэминнәр газабтан котылып мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугъ белән укыйлар, Аллаһтан куркып, кечерәяләр”** (1,2-нче аятьләр) – дигән сүзләреннән алып: **“Вә намазларына сакчыл булырлар. Ошбу кешеләр хокукый җәннәт варисларыдыр. Алар Фирдәүс җәннәтенә варис булырлар һәм алар анда мәңге калырлар”.** (9-11 нче аятьләр). Шулай ук, пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ хәдисен дә китерергә була, ул әйткән: ***“Безнең белән алар[2] арасында килешү – намаз, кем намазны калдырды, шул көферлек кылды”.***

Биш вакыт намазны үтәүдән соң, үзенең мөхимлеге буенча зәкәт бирү килә. Аллаһ Тәгалә Коръәндә әйтте: **“Ә бит аларга Аллаһка ихлас рәвештә хәниф булып гыйбадәт кылырга, намаз үтәргә һәм зәкәт бирергә генә әмер кылынган иде”.** (“Әль-Бәййинә” сүрәсе, 5 нче аять). Шулай ук әйтте: **“Ий мөэминнәр, намазларыгызны тиешенчә үтәгез, зәкәтләрегезне бирегез һәм расүлгә итагать итегез - Аллаһтан рәхмәт ителерсез!”.** (“Ән-Нур” сүрәсе, 56 нчы аять). Аллаһның бөек китабы Көръәндә һәм пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ Сөннәтендә күрәбез – зәкәт бирмәүченең малы Кыямәт көнендә үзенең хуҗасына газапка әйләнәчәк.

Инде, намаз һәм зәкәттән соң үзенең мөхимлеге белән Рамазан аенда ураза тоту килә һәм бу, шулай ук, Ислам диненең биш баганасының берсе булып тора. Пәйгамбәребез ﷺ әйткән:

---

[1] Ләә иләһә иллә-Ллаһ, Мүхәммәдүн расүлү-Ллаһ – “Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичбер иләһ юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе” дип шәһадәт китерү.
[2] Ягъни мөшрикләр.

***«Ислам дине биш тәрәккә нигезләнгән: «Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичбер илаһ юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе» дип шәһадәт бирү, намаз үтәү, зәкят бирү, Рамазан аенда ураза тоту, Хаҗ кылу”.***

Мөэмин-мөселманга үзенең уразасын Аллаһ Тәгалә тыйган сүзләрдән һәм гамәлләрдән ерак торып уздыру тиешле. Чөнки, уразаның асылы – Аллаһка тулысынча буйсыну һәм Аның әмерләрен хөрмәтләү, үзенең нәфесенә каршы тору һәм аны Аллаһның тыйганнарына сабыр булырга өйрәтү. Ягъни ураза ул – ризыктан, судан һәм уразаны бозучы башка әйберләрдән тыелып тору гына түгел! Пәйгамбәребездән ﷺ шундый хәдис килә: ***«Ураза ул – калкан кебек, шуңа күрә, әгәр дә берәрегез берәр көнне ураза тотса, начар һәм буш сүзләр сөйләп, акырып-кычкырып йөрмәсен. Ә инде, берәр кеше сине сүгә башласа яки синең белән сугышырга теләсә, син аңа: “Мин ураза тотам” - дип җавап бир”*** – дигән. Шулай ук, пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***«Кем ураза тотканда ялган сүз сөйләүдән, ялган-буш гамәлләр кылудан һәм үз-үзен наданнар кебек тотудан арына алмый, бу кешенең эчемлек һәм ашавын калдыруыннан Аллаһның хаҗәте юк”.*** Шушы һәм башка аят-хәдисләрдән күрәбез – ураза тотучыга аеруча, Аллаһ Тәгалә тыйган гамәлләрдән ерак булу һәм Аллаһ кушканнарны саклап бару тиешле. Бары тик шулай гына Аллаһ Тәгалә тарафыннан гафу ителүгә, Җәһәннәм газабыннан котылуга, ураза һәм тәравих намазларының кабул булуына өмет итәргә була.

Өстәмә итеп, кайбер кешеләр өчен аңлашылмыйча, яшерен булып калган кайбер мәсьәләләрне аңлатып үтәсе килә.

Шулардан булып – мөэмин-мөселман ураза тотканда, үзенең уразасын Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп ихластан тотарга тиеш. Ягъни уразаны – кешеләр күрсеннәр, ишетсеннәр һәм мине мактасыннар дип рия белән, яки башкаларга ияреп кенә – кешеләр тоталар, мин дә тотыйм әле дип, тотарга ярамый. Кешене ураза тотуга – аның бу гамәлне Аллаһ Тәгалә әмер итте, Аллаһның әҗер-савабына ирешәм дип – иманы этәргеч булырга тиеш. Шулай ук, Рамазан аенда төнге намазлар – тәравих намазларны үтәүне дә, нәкъ шундый ният белән башкарырга кирәк. Шуңа күрә, пәйгамбәребез Мөхәммәд ﷺ әйтеп калдырган: ***“Кем Рамазан аеның [көннәрен] Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп ураза белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер, һәм, кем Рамазан аеның [төннәрен] Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп тәравих намазларын укып уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер, һәм, кем Кадер кичәсен Аллаһка иманлы булып һәм Аның әҗер-савабына өмет итеп гыйбадәт белән уздырса – аның алдагы гөнаһлары кичерелер”,*** – дигән.

Шулай ук, кайбер кешеләр өчен яшерен булып калган кайбер башка мәсьәләләргә килгәндә, болар тора:

Кайбер вакытта ураза тотучының берәр җире яраланса һәм аннан кан килсә, яки борыны канаса, яки күңеле болганып, ихтыярсыз рәвештә, ашаганын кире чыгарса, яки ялгышлык белән су яки бензин йотып җибәрсә, белеп тору кирәк – бу гамәлләр уразаны берничек тә бозмый. Бары тик үз ихтыяры белән ашаганын косып чыгарса гына – уразасы бозыла, чөнки пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Әгәр дә берәрегезнең күңеле болганып ашаганын кире чыгарса – уразаны кайтарып тотарга кирәк түгел, ә инде, үз ихтыяры белән үз-үзен костырса – уразаны кайтарырга кирәк”.***

Тагын бер мәсьәлә: кайбер чакта шундый хәл булуы бар, кеше уразага кергәндә, җөнебз сәбәпле, шулай ук, хатын-кызларның күремнәре яки бала тудырганнан соң килгән каннары таң атканчы туктап, кеше уразага кергәндә госел коенып өлгермәскә мөмкин, чөнки, мәсәлән, күреме булган хатын-кыз таң атыр алдыннан күреме туктаганын аңлый икән – аңа бу көнне ураза тоту тиешле булып тора. Монда нишләргә дигәндә – уразага керүгә госелле булмау каршылык түгел, ягъни госеле булмаса да – уразага керергә кирәк. Ә инде таң ату белән кояш чыккан арада – госел коену тиешле, чөнки иртәнге намаз кояш чыкканчы укыла. Ир-атларга килгәндә, таң атканчы җөнеб хәленнән госел алырга өлгермәсә, таң атканнан соң аларга госел алуны ашыктырырга кирәк, чөнки мәчеткә җәмәгать намазына өлгерәсе бар. Уразаны бозмый торган кайбер гамәлләргә – анализ өчен кан алдыру, дәвалану нияте белән тукландырмый торган уколлар кадату керә. Ләкин, мөмкинчелек булганда, боларны кич белән кояш баеганнан соң эшләү хәерлерәк. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ әйткән: ***“Шикләнгән әйбереңне шикләнмәгән әйбер файдасына калдыр”.*** Һәм, шулай ук: ***“Шикледән сакланучы – динен һәм намусын саклар”,*** – дигән.

Тагын бер мәсьәлә: кешеләрнең булсынмы ул фарыз намазларын, булсынмы сөннәт намазларын тынычлык белән укымау тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең ﷺ хәдисләренә күз салсак – алардан тынычлык белән намаз уку намазның әркәне булып торуын күрәбез, ягъни әгәр дә бу әркән үтәлмәсә – намаз дөрес булмас. Намазда тынычлык саклау – намазны ашыкмыйча, хошуглык белән, тәннең һәрбер сөяген тиешенчә үз урынына кайтарып уку. Бик күп кешеләр, хәтта Рамазан аенда тәравих намазларын укыганда, намазларын аңламыйча, ашыгып, кош җимлек чукыган кебек укыйлар. Мондый намазның Аллаһ Тәгалә тарафыннан кабул ителмичә, әҗер-савапсыз булуы ихтимал.

Тагын бер мәсьәлә: кайбер кешеләрнең тәравих намазы егерме рәкагатьтән дә ким булырга тиеш түгел яки унбер, унөч рәкагатьтән дә арттырырга ярамый дип фикер йөртүләре. Болар, әлбәттә, дәлилләргә каршы килүче ялгыш фикерләр. Чөнки пәйгамбәребезнең ﷺ хәдисләре шуны күрсәтә – кешегә төнге намазларда ирек бирелгән, ягъни нинди дер бер чиген узарга ярамаган рәкагатьләр саны куелмаган. Пәйгамбәребезнең ﷺ үзеннән дә төнге намазларында, булсынмы ул Рамазан аенда яки

---

3 Хатыны белән якынлык кылуы яки төнге поллюциясе сәбәпле госел бозылуы.

башка вакытта, унбер, унөч, яки аннан кимрәк рәкагатьләр үтәве билгеле. Һәм пәйгамбәребезгә ﷺ төнге намазлар турында сорау бирелгәч ул: “ ***[Төнге намазлар] парлап-парлап укыла, ә инде берәрегез таң якынлаша дип курка башласа – укылган намазларын бер рәкагать витр намазы белән тәмамласын”,*** – дигән. Ягъни ул ﷺ төнге намазларга, булсынмы Рамазан аенда яки башка вакытта, ниндидер бер чик куймаган. Шуңа күрә, пәйгамбәребез ﷺ инде исән булмаганда, Гомәр (Аллаһ аннан разый булсын) хәлифә булган вакытта, пәйгамбәребезнең ﷺ сәхабәләре кайчак төнге намазларын егерме өч рәкагать, кайчак унбер рәкагать итеп укыганнар. Болар барысы да Гомәрдән (Аллаһ аннан разый булсын) һәм калган сәхабәләрдән риваять ителә. Шуңа күрә, әвәлге мөселманнарның кайберләре Рамазан аенда утыз алты рәкагать тәравих һәм өч рәкагать витр укыган, кайберләре кырык бер рәкагать укыган. Гыйлем ияләре тарафыннан болар барысы да расланган. Шуңа күрә, галимнәрнең сүзләренә таянып гомумән әйткәндә, әгәр дә кеше тели икән төнге намазларында озак итеп Көръән укырга, озак итеп рокугь-сәҗдәләрен үтәргә – ул чакта рәкагатьләр санын киметсен, ә инде тели икән Көръән укуын, рокугь-сәҗдәләрен җиңеләйтеп-кыскартырга – ул чакта, киресенчә, рәкагатьләр санын арттырсын.

Кем пәйгамбәребезнең ﷺ Сөннәтенә күз салса, бу рәкагатьләр санымнан – Рамазан аендамы яки башка вакыттамы – унбер яки унөч рәкагать итеп уку иң яхшысы булып торганын күрер. Чөнки бу пәйгамбәребезнең ﷺ төнге намазларында иң еш үти торган рәкагатьләр саны. Һәм бу намаз укучылар өчен дә җиңел, ягъни аларны ялыктырмый, намазларын хошуглык, тынычлык белән уку өчен якынрак. Ә кемнең рәкагатьләр санын арттырасы килә, алдан әйтелгәнчә, монда бернинди дә каршылык һәм тыю юк. Ә инде Рамазан аенда мәчеттә имам белән тәравих укучыга намазын имам белән бергә тәмамлау күркәм гамәл. Чөнки пәйгамбәребез ﷺ: ***“Кем [тәравих] намазын имам белән бергә тәмамлый – шуңа төне буе укылган намаз әҗере язылыр”,*** – дигән.

Бу бөек ай – Рамазан аенда – барлык мөселманнарга да төрледән-төрле гамәл-гыйбадәтләрдә тырышлык күрсәтү кирәк, мисал өчен, нәфел намазларын[4] күпләп үтәү, фикерләп - уйланып Көръән уку, күпләп тәсбих[5], тәһлил[6], тәхмид[7], тәкбир[8] әйтү, истигъфар[9] һәм төрле догалар кылу, башкаларны изге гамәлләргә өндәү, начар гамәлләрдән тыю, Аллаһка өндәү, фәкыйрь-мескеннәрне куандыру, ата-анага мәрхәмәт-шәфкатьлелекне арттыру, туганнар белән араны яхшырту, күршеңә хөрмәт күрсәтү, авыру кешенең янына барып хәлен белү, һ.б. бик күп төрле гыйбадәтләр үтәү. Чөнки әлеге айда кылган гамәлләрнең әҗер-сәвабы арттырып биреләчәк! Мисал өчен,

---

4 Мәҗбүри булмаган төрле ирекле намазлар.
5 Сөбхәнәллаһ – “Аллаһ һәр кимчелектән пакъ” – дип әйтү.
6 Лә иләһә иллә-Лаһ, Мүхәммәдүн расүлү-Ллаһ – “Аллаһтан башка гыйбадәт кылырга лаеклы һичбер иләһ юк, Мөхәммәд – Аллаһның илчесе” дип әйтү.
7 Әлхәмдүлилләһ – “Аллаһка барча мактау” – дип әйтү.
8 Аллаһу әкбәр – “Аллаһ һәрнәрсәдән бөек” – дип әйтү.
9 Аллаһтан гөнаһлардан гафу сорау.

пәйгамбәребез ﷺ бер хәдисендә: **“Рамазан аенда гомрә кылу – [үзенең әҗере буенча] Хаҗга тиң”,** яки икенче бер риваятьтә **“минем белән кылган Хаҗга тиң”,** – дигән. Һәм бу айда файдалы, сәваплы гамәлләр кылуда бер-берең белән ярышу кирәклеген күрсәтүче башка бик күп хәдисләр һәм әсәрләр[10] бар.

Аллаһ Тәгаләдән – безне Үзе риза булган сүзләр сөйләүгә һәм гамәлләр кылуга ярдәм итүен, безнең уразаларыбызны һәм тәравих намазларыбызны кабул итүен, барча халәтләребезне яхшылыкка китерүен, адаштыручы яман фетнәләрдән саклавын, мөселманнарның җитәкчеләрен хәерлелеккә кайтаруын, һәм мөселманнарның сүзләрен, хаклыкка туры килгән хәлдә, бер итеп, аларны таркаулыктан бердәмлеккә җыюуын сорыйбыз! Аллаһ Тәгалә генә яклаучы һәм һәрнәрсәгә көче җитүче!

Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

---

10 “Әсәр” - сәхабәләрнең әйткән сүзләре, эшләгән гамәлләре.